Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№12 от 11.05.2023

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген, хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз хайваннарны кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле затларны раслау турында

"Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 498-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 6.1 өлешенә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген раслау (кушымта).

2. Хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Нугаев Мансур Әсхәт улы - Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Иске-Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы М.Ә.Нугаев

ТР Спас муниципаль районы Иске-Рәҗәп авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 11 маендагы 12 номерлы карарына кушымта.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Иске-Рәҗәп авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар
исемлеге

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары, социаль өлкә учреждениеләре һәм күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарына якын территорияләр.

6. Йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.

7. Күп фатирлы йортларга якын территорияләр, аларда мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, шул исәптән күп фатирлы йортларга якын территорияләргә юллар барлыкка китерүче автомобиль юллары.

8. Зиратлар һәм мемориаль зоналар.